**Постановление** **Карар**

**09.02.2016** **13**

**Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 43 статьясы, "Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында" 09.02.2009 ел, № 14-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы муниципаль районнары җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 03.11.2015 ел, №92-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан муниципаль районга керүче җирлекләрдән мәгълүмат җыю буенча, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле " карар бирәм:

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регламентын расларга.

2. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

2.1 Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан һәм вазыйфаи затларыннан, Тәтеш муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан һәм вазыйфаи затларыннан, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиешле муниципаль номатив хокукый актлардан һәм алар турында белешмәләрдән җыюны гамәлгә ашырырга һәм аларны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына билгеләнгән тәртип, регламент нигезендә җибәрүне тәэмин итәргә.

2.2 муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү өчен җаваплы затны регистрга кертү өчен билгеләргә.

2.3. Регистрны оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка чаралар күрергә.

3. Район Советы аппаратына, Финанс-бюджет палатасына, Тәтеш муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына тәкъдим итәргә:

Регистрны оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль норматив хокукый актларны һәм башка чараларны кабул итәргә.

Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Башлык Р.Х. Сафиуллов